ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2022 Олы Кайбыч ав. № 57

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында һәм «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 05 августындагы 655 номерлы карары нигезендә Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмәгә кушымтада бирелгән редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 е. «7» февралендәге
57 номерлы карарына кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмә**

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы өчен айлык окладка өстәмә түләүдән, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган хезмәт хакына айлык өстәмә түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум<br>муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 24 411 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 22 145 |
| Бүлек җитәкчесе | 18 231 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 15 759 |
| Бухгалтер | 14 420 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия штат расписаниесенә муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары штаты кертү шарты булып, структурада һәрберсендә кимендә 5 берәмлек штат булган кимендә 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.

4. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә:

1) түбәндәге размерларда тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләү:

| эш стажы | айлык өстәмә түләү, процент |
|---|---|
| 1 - 5 ел | 5 |
| 5 - 10 ел | 7 |
| 10 - 15 ел | 10 |
| 15 елдан артыграк | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләү;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү;

Әгәр хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәгән булса, бер тапкыр бирелә торган түләү исәпләнә һәм аңа декабрьдә башкарылган вакытка пропорциональ рәвештә, эштән чыгарылган очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Еллык түләүле отпуск биргәндә хезмәткәргә бер тапкыр түләнә торган түләү беренче эш елында календарь елда башкарылган чорга пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы календарь елның 31 декабре буенча эшкә кергән көннән исәпләнә.

4) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

5) хезмәт хакының бер проценты күләмендә айлык премия, хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премия (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләме чикләнми) билгеләнә.

Җитәкче өчен премиянең күләме гамәлгә куючы, учреждение хезмәткәре өчен җитәкче тарафыннан билгеләнә.

5. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакының еллык фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \text{Р} * (1 + t);$$

монда:

$FOT$ – җитәкчеләр һәм белгечләр хезмәт хакының еллык фонды;

$O_d$ – җитәкчегә һәм белгечкә аена вазыйфаи окладларны түләүгә акчалар суммасы;

$0{,}3 * O_d$– тиешле елларны эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпускны биргәндә бер мәртәбә бирелә торган түләү, матди ярдәм күрсәтү өчен акча суммасы;

Р – җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык премия фонды (*әлеге Нигезләмәнең 3 пунктының 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә*);

$n$ – җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт өчен түләү буенча түләүләр.